РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» декабрь 2023 ел г. Альметьевск № 190

Әлмәт муниципаль районы Башлыгының
кайбер карарларының үз көчләрен
югалтуын тану турында

Муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

КАРАР БИРӘМ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башлыгының карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

- «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының норматив хокукый актларын, законсыз карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлгә яраксыз дип тану турында законлы көченә кергән суд, арбитраж судларның закон көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау тәртибе турында» 2018 елның 26 ноябрендәге 152 номерлы;

- «Әлмәт муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарының, район составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарының һәм күрсәтелгән органнарның вазыйфаи затларының норматив хокукый актларын, законсыз карарларын һәм гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлгә яраксыз дип тану турында законлы көченә кергән суд, арбитраж судларның закон көченә кергән карарлары нәтиҗәләре буенча хокук куллану практикасы мәсьәләләрен карау тәртибе турында» 2018 елның 26 ноябрендәге 152 номерлыкарарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 13 апрелендәге 33 номерлы.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең хокук мәсьәләләре буенча урынбасары Д. С. Яфизовка йөкләргә.

Муниципаль район
Башлыгы Т.Д. Нагуманов

Р.05-12058/12
СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНН 1644035766
КПП 164401001
ОГРН 1051605066952